ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 558-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Зарипов, Л.Н. Рыбакова, М.Х. Сәлахов, Н.М. Гафиятуллин тарафыннан кертелгән «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 558-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2520-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Р. Зарипов, Л.Н. Рыбакова,
М.Х. Сәлахов,
Н.М. Гафиятуллин
тарафыннан кертелә

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 өлештә «белемнең сыйфатын бәяләү» сүзләрен «белем сыйфатын бәяләү чаралары» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ и $3^2$ өлешләр өстәргә:

«$3^1$. Мәгариф системасына мониторингны гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелә торган белем сыйфатын бәяләү чараларына гомуми белем сыйфатын региональ, илкүләм һәм халыкара чагыштырып тикшерүләр, шулай ук белем сыйфатын бәяләү буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан исемлеге һәм үткәрү тәртибе билгеләнә торган (региональ чаралардан тыш) башка чаралар керә.

$3^2$. Гомуми белем сыйфатын региональ чагыштырып тикшерүләр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы карары белән үткәрелә. Региональ чагыштырып тикшерүләрнең исемлеге, федераль башкарма хакимиятнең мәгариф өлкәсендә тикшерү һәм күзәтчелек итү функцияләрен башкара торган органы белән килештереп, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керәчәк «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 97 һәм 98 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 468-ФЗ номерлы Федераль закон белән мәгариф системасына мониторинг үткәрү мәсьәләләренә кагылышлы үзгәрешләр кертелде. Кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, белем сыйфатын бәяләү чаралары региональ, илкүләм һәм халыкара чагыштырып тикшерүләр рәвешендә үткәрелә. Илкүләм һәм халыкара чагыштырып тикшерүләрнең исемлеге һәм аларны үткәрү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә. Гомуми белем сыйфатын региональ чагыштырып тикшерүләр, федераль башкарма хакимиятнең мәгариф өлкәсендә тикшерү һәм күзәтчелек итү функцияләрен башкара торган органы белән килештереп, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы карары белән үткәрелә.

Шуңа бәйле рәвештә «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итми.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.